**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№6286**
**23.10.2018**

Төрләре Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә торган объектларны урнаштыру өчен җир участоклары бирмичә һәм сервитутлар билгеләмичә, дәүләт яки муниципаль милектәге җирләрне яисә җир участокларын файдалануга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ санлы Федераль закон, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 нче карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезнамәнең 5.24 пункты, Башкарма комитетның 2011 елның 30 мартындагы 1576 нчы карары белән расланган Башкарма комитет тарафыннан күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләрнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе турында нигезнамә нигезендә

К А Р А Р   Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2017 елның 26 апрелендәге 2566 нчы карары белән расланган төрләре Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә торган объектларны урнаштыру өчен җир участоклары бирмичә һәм сервитутлар билгеләмичә, дәүләт яки муниципаль милектәге җирләрне яисә җир участокларын файдалануга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына (алга таба – административ регламент) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1.4 пунктта:

- түбәндәге эчтәлектәге абзац белән тулыландырырга:

«Күчемсез милекне дәүләт теркәвенә алу турында» 2015 елның 13 июлендәге 218-ФЗ санлы Федераль закон (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 20.07.2015, №29 (I бүлек) ст. 4344) (алга таба – 218-ФЗ санлы Федераль закон)»;

- 11 пунктчаны яңа редакциядә бәян итәргә:

«11) Башкарма комитетның 2017 елның 28 декабрендәге 1210-р санлы боерыгы белән расланган Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе турында нигезнамә (алга таба – Идарә турында нигезнамә);»;

- 2.1 пунктны «РФ Хөкүмәте Карары» сүзләреннән соң «Башкарма комитетның 2016 елның 13 маендагы 2363 нче карары» сүзләре белән тулыландырырга;

2) 2.5 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| 2.5. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булып торган, норматив хокукый актлар нигезендә муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм гариза бирүче тапшырырга тиешле документларның тулы исемлеге | 1) Гариза (1 нче кушымта);<br>2) аның урнашу урынын һәм күрше җир участокларының урнашу урынын билгеләргә мөмкинлек бирә торган җир участогында объектларның урнашу схемасы (1:500 масштабта ситуация планы, адрес);<br>3) гариза бирүченең һәм гариза бирүче вәкиленең шәхесен раслаучы документларның һәм, гариза гариза бирүченең вәкиле тарафыннан бирелгән очракта, гариза бирүченең вәкиленең вәкаләтләрен раслаучы документ күчермәләре | ТР Министрлар Кабинеты Карары |

3) 2.6 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| 2.6. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагындагы һәм гариза бирүче тапшырырга хокуклы документларның тулы исемлеге | 1) Бердәм дәүләт юридик затлар реестрыннан өземтә (гариза бирүче булып юридик зат торган очракта);<br>2) Бердәм дәүләт шәхси эшмәкәрләр реестрыннан өземтә (гариза бирүче булып шәхси эшмәкәр торган очракта);<br>3) Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә;<br>4) объектларны урнаштыруга Башкарма комитетның ризалыгы – объектны урнаштыру Татарстан Республикасы милкендәге җир | № 218-ФЗ санлы Федераль закон;<br>2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ санлы Федераль законның 7, 7.1 маддәләре;<br>ТР Министрлар Кабинеты Карары |

| | | |
|---|---|---|
| | участокларында гамәлгә ашырылган очракта;<br>5) объектларны урнаштыру проектын техник-икътисадый нигезләү яки кирәкле исәп-хисаплар;<br>6) планлаштырыла торган җир участогында объектлар урнаштыру кирәклегген раслаучы башка документлар | |

4) 2.7 пунктның 2 пунктчасын төшереп калдырырга;

5) 3.4.1 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«3.4.1. ҖММИ белгече ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша электрон рәвештә әлеге Регламентның 2.6 пунктында күрсәтелгән документларны бирү турында запрос җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар гариза кергән вакыттан башлап бер эш көне эчендә ҖММИ белгече тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: әлеге Регламентның 2.6 пунктында күрсәтелгән документларны бирү турында ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша җибәрелгән запрослар.»;

6) 3.4.3 пунктны төшереп калдырырга;

7) 4.2 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«4.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү буенча административ процедуралар белән билгеләнгән гамәлләр эзлеклелегенең үтәлешен агымдагы контрольдә тоту Башкарма комитет Җитәкчесе тарафыннан гамәлгә ашырыла.»;

8) 5 бүлекнең исемен яңа редакциядә бәян итәргә:

«5. Башкарма комитетның, аның вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләрнең, шулай ук КФҮнең, КФҮ хезмәткәрләренең карарларына һәм эш итүләренә (эш итмәүләренә) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү тәртибе»;

9) 5.1 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«5.1. Муниципаль хезмәттән файдаланучылар Башкарма комитетның муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы хезмәткәрләренең карарларына, эш итүләренә (эш итмәүләренә) судка кадәр тәртиптә – Башкарма комитетка, КФҮ хезмәткәрләре буенча – КФҮгә яисә КФҮне оештыручы булып исәпләнгән гавами-хокукый берәмлекнең тиешле дәүләт хакимияте органына (җирле үзидарә органына) шикаять бирергә хокуклы.

Гариза бирүче шикаять белән мөрәҗәгать итәргә мөмкин, шул исәптән түбәндәге очракларда:

1) муниципаль хезмәт күрсәтү турында запросны, 210-ФЗ санлы Федераль законның 15.1. маддәсендә күрсәтелгән запросны теркәү срогын бозу;

2) муниципаль хезмәт күрсәтү срогын бозу;

3) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен гариза бирүчедән тапшыру яки гамәлгә ашыру Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив хокукый актларында, Яр Чаллы шәһәре

муниципаль берәмлегенең хокукый актларында каралмаган документлар яки мәгълүмат яисә эшләрне гамәлгә ашыруны таләп итү;

4) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен гариза бирүчедән Россия Федерациясенең хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда тапшыру каралган документларны кабул итүдән баш тарту;

5) баш тарту өчен нигезләр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасының законнарында һәм норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда каралмаган очракта, муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту;

6) муниципаль хезмәт күрсәткәндә гариза бирүчедән Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда каралмаган түләү таләп итү;

7) муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче орган вазыйфаи затының, КФҮнең, КФҮ хезмәткәренең муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән ялгышларны һәм хаталарны төзәтүдән баш тарту яисә андый төзәтүләрнең билгеләнгән срогын бозу;

8) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре буенча документлар бирү срогын яки тәртибен бозу;

9) муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату нигезләре федераль законнарда һәм аларга туры китереп кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм башка норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда каралмаган очракта, муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату;

10) дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәткәндә гариза бирүчедән 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ санлы Федераль законның 7 маддәсендәге 1 бүлекнең 4 пунктында каралган очраклардан тыш, дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтүдән яисә дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән беренчел баш тартканда булмавы һәм (яки) дөрес булмавы күрсәтелмәгән документларны яки мәгълүматны таләп итү.»;

10) 5.2 һәм 5.3 пунктларны яңа редакциядә бәян итәргә:

«5.2. Шикаять язма рәвештә кәгазьдә яки электрон төрдә бирелә.

Шикаять почта аша, КФҮ аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтыннан (http://www.nabchelny.ru), КФҮнең рәсми сайтыннан, Татарстан Республикасының бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан (http://uslugi.tatar.ru/), Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталыннан (http://www.gosuslugi.ru/) файдаланып җибәрелергә мөмкин, шулай ук гариза бирүчене шәхси кабул иткәндә кабул ителергә мөмкин.

5.3. Шикаятьне карап тикшерү срогы – ул теркәлгән көннән башлап унбиш эш көне эчендә. Башкарма комитетның, КФҮнең гариза бирүчедән документларны кабул итүдән яисә җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартуыннан риза булмыйча шикаять бирелгән очракта яки

шундый төзәтүләрнең билгеләнгән срогы бозылудан риза булмыйча шикаять бирелгән очракта – ул теркәлгән көннән башлап биш эш көне эчендә.»;

11) 5.4 пунктта:

- 1 пунктчаны «Башкарма комитетның муниципаль хезмәткәре» сүзләреннән соң «, КФҮ, аның җитәкчесе һәм (яки) хезмәткәре» сүзләре белән тулыландырырга;

- 3 пунктчаны «, КФҮ, КФҮ хезмәткәре» сүзләре белән тулыландырырга;

- 4 пунктчаны «, КФҮ, КФҮ хезмәткәре» сүзләре белән тулыландырырга;

12) 5.7 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«5.7. Шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документлардагы хаталарны һәм ялгышларны төзәтү, Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында, Россия Федерациясе субъектларының норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда түләтү каралмаган акчаларны гариза бирүчегә кире кайтару рәвешендә;

2) шикаятьне канәгатьләндерү кире кагыла.»;

13) 5.8. пунктны түбәндәге эчтәлектәге икенче һәм өченче абзаслар белән тулыландырырга:

«Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип танылган очракта, гариза бирүчегә Регламентның 5.7 пунктында күрсәтелгән җавапта, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә ачыкланган кимчелекләрне тиз арада бетерү максатында Башкарма комитет, КФҮ яисә 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ санлы Федераль законның 16 маддәсендәге 1.1 бүлегендә каралган оешма тарафыннан гамәлгә ашырыла торган эшләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук тудырылган уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм дәүләт яки муниципаль хезмәттән файдалану максатында гариза бирүче башкарырга тиешле алдагы гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш түгел дип танылган очракта, гариза бирүчегә Регламентның 5.7 пунктында күрсәтелгән җавапта кабул ителгән карар сәбәпләре турында дәлилләнгән аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат бирелә.»;

14) 5.9 һәм 5.10 пунктларны яңа редакциядә бәян итәргә:

«5.9. Шикаять тулысынча яки өлешчә канәгатьләндерелгән очракта, кимчелекләрне бетерү максатында кабул ителергә тиешле чаралар билгеләнә.

Шикаятьләрне карап тикшерү барышында яки аның нәтиҗәләре буенча административ хокук бозулар яки җинаять составы билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карап тикшерү вәкаләтләре бирелгән вазыйфаи зат, хезмәткәр булган материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына җибәрә.

5.10. Гариза бирүчеләр Башкарма комитетның, аның вазыйфаи затларының, шулай ук КФҮнең, КФҮ хезмәткәрләренең карарларына, эш итүләренә (эш итмәүләренә) Россия Федерациясе законнары нигезендә суд тәртибендә шикаять бирергә хокуклы.»;

15) кушымтаны (белешмә) 1 нче кушымтада каралганча яңа редакциядә бәян итәргә;

16) 3 нче кушымтаны 2 нче кушымтада каралганча яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Административ регламентның 5.1 пунктындагы 3, 10 пунктчалар, 5.8 пунктындагы икенче һәм өченче абзацлар 2018 елның 18 октябреннән үз көченә керә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе башлыгы Л.Р. Гыйззәтуллинга йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллин

Башкарма комитетның
2018 елның 23 октябрендәге
6286 нчы карарына
1 нче кушымта

Төрләре Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә торган объектларны урнаштыру өчен җир участоклары бирмичә һәм сервитутлар билгеләмичә, дәүләт яки муниципаль милектәге җирләрне яисә җир участокларын файдалануга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына кушымта (белешмә)

Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен җаваплы
һәм аның үтәлешен контрольдә тотуны гамәлгә ашыручы вазыйфаи затларның
реквизитлары


| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Башкарма комитет Җитәкчесе | 30-55-42 | kancel.chelny@tatar.ru |
| Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе башлыгы | 30-55-54 | uzioIP@ya.ru |
| Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе башлыгы урынбасары | 30-55-54 | uzioIP@ya.ru |
| Башкарма комитет җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсенең аренда мөнәсәбәтләрен җайга салу бүлеге башлыгы | 30-55-54 | uzioIP@ya.ru |
| Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе бүлеге белгече | 30-55-54 | uzioIP@ya.ru |


Башкарма комитет Аппараты Җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы Н.И. Галиева


Башкарма комитетның
2018 елның 23 октябрендәге
6286 нчы карарына
2 нче кушымта

Төрләре Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә торган объектларны урнаштыру өчен жир участоклары бирмичә һәм сервитутлар билгеләмичә, дәүләт яки муниципаль милектәге жирләрне яисә жир участокларын файдалануга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына
3 нче кушымта

Муниципаль хезмәт күрсәтү буенча гамәлләр эзлеклелегенең блок-схемасы




Теркәлгән документлар белән бергә Башлыкка җибәрелгән гариза
ҖММИ башлыгы гаризаны һәм документларны карап тикшерә, үтәүчене билгели һәм үтәү өчен ҖММИ бүлеге белгеченә җибәрә
ҖММИ бүлеге белгеченә җибәрелгән гариза һәм документлар
ҖММИ бүлеге белгече ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша документларны соратып алу кирәклеген билгели
Документларны соратып алу кирәклеге
Юк
Әйе
ҖММИ бүлеге белгече запрослар җибәрә
Мәгълүматлар бирү турында запрос
Мәгълүмат бирүчеләрнең белгечләре запросларны эшкәртәләр һәм мәгълүматларны бирәләр яки документлар (мәгълүматлар) булмау турында белдерү кәгазе җибәрәләр
Документлар (мәгълүматлар) яки документлар (мәгълүматлар) булмау турында белдерү кәгазе
ҖММИ бүлеге белгече алынган документлар (мәгълүматлар) нигезендә:
1) карар проектын әзерләүне гамәлгә ашыра һәм килешенү өчен ҖММИ бүлеге башлыгына җибәрә;
2) кире кагу турында хат әзерләүне гамәлгә ашыра һәм имзалау өчен ҖММИ бүлеге башлыгына җибәрә
Килешү проекты яки кире кагу турында хат
ҖММИ башлыгы карар проектын карап тикшерә:
1) карар проектын килешенә һәм килешенү өчен аны Башкарма комитетның хокук идарәсенә җибәрә;
2) кире кагу турында хатны имзалый һәм әлеге хатны эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә җибәрә;
Имзаланган һәм эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә җибәрелгән кире кагу турында хат яисә килешенгән һәм Башкарма комитетның хокук идарәсенә җибәрелгән карар проекты




Башкарма комитет Аппараты Җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы Н.И. Галиева